ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2021 г. Заинск № 428

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 февралендәге 265 номерлы һәм 2018 елның 19 декабрендәге 1881 номерлы карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында**

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставына таянып, гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:
1.1. «Өченче затка җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча җир кишәрлеген арендалаучының хокукларын һәм бурычларын тапшыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 29 февралендәге 265 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.
1.2. «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 29 февралендәге 265 номерлы карары белән расланган өченче затка җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча җир кишәрлеген арендалаучының хокукларын һәм бурычларын тапшыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 декабрендәге 1881 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.
2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшмәкәрлеккә ярдәм буенча урынбасары Р.М. Архиповага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

юрист

Р.Р. Шәйхиев
2 80 31